**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 декабрь № 929

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

4.1.5 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

4.1.21 нче пунктның бишенче абзацында «һәм укыту-өйрәтү» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.22 нче пунктның икенче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә» сүзләрен «хәрби низаглар булганда яки әлеге низаглар нәтиҗәсендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.23 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданнар оборонасы буенча төбәк дәрәҗәсендәге чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмалар исемлеген билгеләү буенча.»;

4.1.25 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хәрби низаглар булганда яки әлеге низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан саклану ысуллары, шулай ук гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар шартларында саклану ысуллары һәм гамәлләре буенча халыкны әзерләү.»;

4.1.26 нчы пунктның икенче абзацында «укыту-өйрәтү» сүзен «әзерләү» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасында «Вазыйфаи затларны әзерләү һәм халыкны укыту-өйрәтү бүлеге» сүзләрен «Вазыйфаи затларны һәм халыкны әзерләү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\929.doc